КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 30 март г.Казань № 380

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар турында» 2013 ел, 29 август, 614 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 11 ноябрь, 866 нчы; 2014 ел, 8 май, 304 нче; 2014 ел, 17 май, 330 нчы; 2014 ел, 26 декабрь, 1032 нче; 2016 ел, 17 февраль, 98 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 733 нче; 2018 ел, 20 март, 159 нчы; 2019 ел, 8 апрель, 274 нче; 2019 ел, 21 май, 427 нче; 2019 ел, 2 октябрь, 886 нчы; 2019 ел, 31 октябрь, 985 нче; 2019 ел, 24 декабрь, 1186 нчы; 2020 ел, 25 февраль, 140 нчы; 2020 ел, 1 апрель, 248 нче; 2020 ел, 27 май, 428 нче; 2022 ел, 31 март, 295 нче, 2022 ел, 29 сентябрь, 1045 нче, 2022 ел, 29 декабрь, 1447 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирүгә республика конкурсын үткәрү буенча оештыру комитеты составында Гарипов Илнур Мәхмүт улы вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенең беренче урынбасары –Татарстан Республикасы Рәисенең Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы

поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирүгә республика конкурсын үткәрү буенча оештыру комитеты турындагы нигезләмәнең 1.2 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында» 2015 ел, 1 июнь, 391 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 13 сентябрь, 636 нчы; 2017 ел, 15 май, 282 нче; 2018 ел, 5 февраль, 59 нчы; 2018 ел, 4 апрель, 205 нче; 2018 ел, 5 сентябрь, 757 нче; 2019 ел, 27 февраль, 130 нчы; 2019 ел, 2 октябрь, 886 нчы; 2019 ел, 31 октябрь, 987 нче; 2019 ел, 25 декабрь, 1191 нче; 2020 ел, 2 март, 155 нче; 2021 ел, 12 гыйнвар, 7 нче; 2021 ел, 23 декабрь, 1274 нче; 2023 ел, 30 гыйнвар, 70 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында нигезләмәгә 3 нче кушымтаның 5 пунктындагы 3 графасында «Россия Федерациясе Пенсия фондының тиешле бүлекчәләре» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминләштерү фонды» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсын уздыру буенча конкурс комиссиясе составында Гарипов Илнур Мәхмүт улы вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенең беренче урынбасары –Татарстан Республикасы Рәисенең Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар акчасы исәбеннән финанс ярдәме күрсәтүдән файдалану өчен тәкъдим ителә торган инициативалы проектларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү тәртибен, Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар акчасы исәбеннән финанс ярдәме күрсәтүдән файдалану өчен тәкъдим ителә торган инициативалы проектларны карап тикшерү буенча конкурс комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау хакында» 2021 ел, 5 июль, 545 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 9 август, 783 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар акчасы исәбеннән финанс ярдәме күрсәтүдән файдалану өчен тәкъдим ителә торган инициативалы проектларны карап тикшерү буенча конкурс комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составыннан Е.А.Барабанованы, Т.И.Саматовны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Карпов Родион Михайловичны | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасарын |

| | |
|---|---|
| Сафина Гөлнара Марат кызын | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасарын; |

Гарипов Илнур Мәхмүт улының вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенең беренче урынбасары –Татарстан Республикасы Рәисенең Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин